Татарстан республикасы
Чүпрәле  муниципаль районы
“Иске Шәйморза гомуми урта
белем  бирү мәктәбе” муниципаль
бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

# “Мин татарча сөйләшәм”

республикакүләм акциясендә катнашуы
турында
отчеты

**Акцияне  үткәрде: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Насибуллова Фәридә Шамил кызы**

**2015ел**

мин татарча сөйләшәм!

# Безнең девиз:

***Татар телен  ныклап үстерү,***
***Һәр кешенең күңеленә шушы фикерләрне***
***йөрәк аша җиткерү!!!***

# Безнең максат:

- ***Яшь буынны татарча сөйләшергә өндәү;***
- ***Кибет, урам һәм башка урыннарда татар теле кулланылышын активлаштыру ;***
- ***Татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү;***

# “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе үткәрү планы

| № | вакыты | Үткәреләчәк чаралар | Җаваплылылар |
|---|---|---|---|
| *1* | *21.02* | *“Мин татарча сөйләшәм” акциясе үткәрү программасы белән таныштыру һәм кабул итү, планын төзү* | *Ибятова З.Ә.(тәрбия эшләре буенча дирекектор урынбасары)* |
| *2* | *25.02* | *“Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар” темасына үткәрелгән 3 республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә катнашу* | *Арсланова З.Җ.(Татар теле һәм әдәбияты укытучысы)* |
| *3* | *Акция дәвамында* | *Татар теле һәм аның әһәмияте турында әңгәмәләр үткәрү* | *Сыйныф җитәкчеләре* |
| *4* | *Акция дәвамында* | *“Минем тормышымда татар теле” темасына иншалар, рефератлар шигырьләр яздыру* | *Татар теле һәм башлангыч сыйныф укучылары* |
| *5* | *март* | *Рус телле балалар арасында “Татарча экият һәм шигырьләр” конкурсы үткәрү* | *Насибуллова Ф.Ш. Һәм Гайнетдинева Г.А. (татар теле һәм әдәбияты укытучылары)* |
| *6* | *март* | *“Ачык микрофон” көне үткәрү* | *Татар теле һәм әдәбияты укытучылары* |
| *7* | *20.03* | *Нәүрүз бәйрәме үткәрү* | *Прохорова А.Р.(рус теле һәм әдәбияты укт учысы)* |
| *8* | *2.04* | *Башлангыч сыйныфларда рус телле балалар арасында телгә багышланган викторина үткәрү* | *Камалова Г.Н. Һәм Гайнетдинова Г.А. (Башлангыч сыйныф укытучылары)* |

| № | вакыты | Үткәреләчәк чаралар | җаваплылар |
|---|---|---|---|
| *9* | *апрель* | *5-6 нчы сыйныфларда “Мин татарча сөйләшәм” акциясенә карата Г. Тукайга багышланган бәйрәм үткәрү* | *Насибуллова Ф.Ш. (Татар теле һәм әдәбияты укытучысы)* |
| *10* | *3.04* | *Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән “Зирәк тиен” конкурсына әзерләнү* | *Фәтхуллина М.Җ. (Татар теле һәм әдәбияты укытучысы)* |
| *11* | *6.04* | *“Газиз телем гасыр диңгезләрен кичә-кичә килгән ерактан...” темасына акциянең йомгаклау кичәсен үткәрү* | *Татар теле һәм әдәбияты укытучылары* |


“Мин татарча сөйләшәм” акциясен үткәрүдә 146 кеше катнашты. Куелган барлык максат һәм бурычларыбыз үтәлде. Шул сәбәпле, яшь буынны татарча сөйләшергә өндәү; Кибет, урам һәм башка урыннарда татар теле кулланылышын активлаштыру ; Татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү кебек эшләр башкарылды.



***…Тормыш ыгы-зыгысыннан туктап,***
***Мәшәкатьләреңне ташла да,***
***Әй, туганым, үткәнеңә кара,***
***Анда синең нәселең башлана.***
***Ерак бабайлардан аваз килә:***
***“Тамырыңны өйрән, и бала.***
***Онытa күрмә, нинди җепләр белән***
***Кеше заты җирдә саклана…***

***…Тормыш ыгы-зыгысыннан туктап,***
***Мәшәкатьләреңне ташла да,***
***Әй, туганым, үткәнеңә кара,***
***Анда синең нәселең башлана.***
***Ерак бабайлардан аваз килә:***
***“Тамырыңны өйрән, и бала.***
***Онытa күрмә, нинди җепләр белән***
***Кеше заты җирдә саклана…***

*Халык бәйрәмнәрен саклап калу, аларны кабат җанландыру, өйрәнү, җәмгыятебезнең бәйрәм культурасын баета, халыклар дуслыгын ныгыта. Туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү - безнең төп бурычыбыз. Шуңа күрә без мәктәптә "Мин татарча сөйләшәм" акциясенә багышланган кичәләр, дәресләр, дәрестән тыш чаралар үткәрергә тырышабыз. Шул рәвешле милләтара дуслыкны ныгытып, татар телен саклап калу һәм республикабыздагы милләтләрнең зур бер гаилә булып яшәвендә милли бәйрәм, йола, гореф-гадәтләрнең роле зур икәнлегенә инанабыз. 18 мартта мәктәбебездә әлеге акциягә карата "татар халкының гореф-гадәтләре һәм башка милләт вәкилләренең бәйрәм-йолалары арасындагы уртак һәм аермалы яклары" темасына рус телле балалар өчен 7 нчы сыйныфта дәрес-әңгәмә үткәрелде*








Милләтемнең киләчәге!
Һәр милләт кешесе өчен иң моңлы көй – үзенең милли көе, иң матур, иң кадерле тел – үзенең туган теле... Туган телебез татар теле – борынгы һәм һәрьяклап үсеш алган телләрнең берсе. Ул – мул сүзлек хәзинәсе, бай тел. Тел һәм моң – күңелебезнең көзгесе ул.Үз телеңне белмәү, аны санламау – зур кимчелек дип уйлыйм мин.  Татар халкының әдәп–кагыйдәләре, гореф–гадәтләре, йолалары, милли уеннары, безнең барыбызга да таныш, әмма ни дәрәҗәдә соң? Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре, йолалары, кабатланмас гореф-гадәтләре бар. Алар халыкта милли горурлык, милли хисләр культурасы тәрбияләргә ярдәм итә. Татар халкының бик күп йолалары халык хәтерендә, өлкән буын кешеләренең истәлекләрендә сакланып килә. Бу хәзинәнең зур өлеше инде, кызганыч, гадәти көнкүрештә кулланылмый да. Авыл халкын бергә җыю, шәһәр халкын туган ягына тарту, өлкән буын белән яшь буынны, элекке дусларны, танышларны очраштыру өчен бу бик мөһим, әһәмиятле һәм кирәкле вакыйга.  Безнең халкыбызга җыр-биюгә, уен-көлке, тапкыр сүзгә осталык белән бергә тырышлык, уңганлык, кунакчыллык хас. Алар буш вакытларын гаиләгә, киләчәккә, милләткә файдалы эшләр   башкарып үткәннәр. Бүгенге көндә яшьләр буш вакытларын төрлечә үткәрә, ял итүне дә һәркем үзенчә аңлый. Татар халкының гореф-гадәтләре һәм гомумән йолалар, бәйрәмнәр турында тикмәгә генә сүз башламадым...

Кулларыңа каләм алдың,
Әй, нурлы бала.
Сурәт сыздың, шигырь яздың,
Син – нурлы бала!
Шигырьләрең җырга күчте
Әй, нурлы бала.
Иҗнәреңә канат үсте –
Син – нурлы бала!
(Э. Шәрифуллина)





“Татар баласы-2015”конкурсы күптәннән мәктәп күләмендә генү түгел , ә район, республикакүләм үткәрелә торган чараларның берсе. Бу бәйге бездә дә булып үтте.Без шушы конкурста үзен милләтенең тугрылыклы бер вәкиле итеп тойган татар дөньясындагы барлык вакыйгалар белән дә даими танышып, шуның эчендә кайнап яшәргә тырышкан, дөньяда үз сүзен әйтергә омтылган зирәк, уңган, татар халкына хас тыйнаклык сыйфатларын үз эченә алган укучылыр татар балалары белән танышып үттек. Алар үзләрен төрле яктан да өлгер, уңган һәм рухи яктан көчле чын татар кызлары икәнлегенә безне инандырдылар.

Бәйге өч өлештән торды:

1.Презентация(минем татар теленә керткән ролем)

2.Татар халык йоласы(ягъни укучы татар халкының бер йоласын сөйләп китәргә яки сәхнәләштерергә тиеш иде)

3. Минем шөгылем (Укучының буш вакытларында ниләр белән шөгыльләнүе турында мәгълумат бирелергә тиеш иде)



Конкурс бик матур һәм мәгънәле үтте. Барлык өлешләрдә дә кызлар, егетләр үзләренең осталыкларык берсеннән-берсе уздырып күрсәтергә тырыштылар. Һәр укучы тамашачыны үзенең һөнәре белән сокланрыра алды. Укучыбыз Әхтәмов рәсим татар халкының “балага исем кушу йоласы”н сөйләп кенә калмыйча сәхнәләштереп күрсәтүдә дә катнашты . Без монда аның ничек итеп сәхнәдә үз-үзен тотышын, рольне үтемле итеп башкаруын күрдек. Шулай ук ул үзенең сәнгатькә бирелгәнлеген татар халык биюен башкарганда да бию элементлары аша, жест һәм мимика аша да җиткерә алды.

Бу бәйгедә иң булган, уңган " Татар баласын " аерып алу, әлбәттә, җиңел булмады. Бу җаваплы эш үтә таләпчән, гаять гадел жюри әгъзаларына йөкләнгән иде. Әмма, барыбер нәтиҗәләр ясап урын билгеләргә кирәк. Барлык конкурс этапларына да күзәтү ясалгач, алар уртак фикергә килеп урыннар билгеләнде.

I урын-Рәсим әхтәмов яулады(Иске Шәйморза урта мәктәбе)

Югарыдагылардан чыгып түбәндәге нәтиҗәләрне ясап була: димәк, безнең киләчәгебез өметле, мондый татар балалары булганда безнең татар халкы үлмәячәк, киресенчә ул яңа көчләр туплап оскә омтылачак, яңа үрләрне яулаячак!!!

мин татарча сөйләшәм!

***“Минем тормышымда татар  теле” темасына иншалар, рефератлар шигырьләр яздыру***







***Кышны озатып, Нәүрүзбикәне каршы алу күренеше***

мин татарча сөйләшәм!

***Акция дәвамында сыйныф җитәкчеләре тарафыннан татар теле һәм аның әһәмияте турында әңгәмәләр үткәрелде***









***Туган телебез - татар теле, зур тарихлы, бай, җырлы, моңлы тел! Туган тел! Һәркем өчен дә газиз бу сүз. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә чагыштырып булмый торган әни, әти, туган ил сүзләрен туган телдә әйтәбез.Туган йортыбызның, туган авылыбызнын, туган илебезнең кадерле булуын без иң элек туган тел аша тоябыз. Безне серле хыял иленә алып кергән әкиятләребезне, тапкыр һәм җор телле булырга өйрәткән табышмак һәм мәкальләребезне, моңлы һәм хисле иткән җырларыбызны туган телдә ишетәбез.***

***Русс телле балалар арасында “Татарча әкият һәм шигырьләр” конкурслары үткәрү. Әсәрләрдән өзекләр күрсәтү***









***Җырласаң да, җегет, ачы җырла,***
***Уяу җаткан кызлар җокласын;***
***Тәрәзәләр ачтым, гөлләр сачтым,***
***Асыл кошлар килеп***

***И туган тел, и матур тел,***
***Әткәм-әнкәмнең теле!***
***Дөньяда күп нәрсә белдем***
***Син туган тел***

мин татарча сөйләшәм!

*“Ачык микрофон” көне үткәрү*







***Укучылар, кибеттә, даруханәдә,  шифаханәдә,***
***почта бүлекчәләрендә***
***татарча гына сөйләштеләр***






***Шулай ук  китапханәдә,  ашханәдә дә укучыларның***
***Татар телен кулланулары шатландыра...***





***Китапханәче Илһамия апалары рәхәтләнеп укучыларның сорауларына татарча җавап бирә***



Татар халкының элек - электән китап сүзенә хөрмәт белән каравы, аны кадерләп яшәве, яраткан китапны кулдан-кулга йөртүе, газетада берәр кызыклы мәкалә чыкса, аны күмәк укып фикерләшүе буенча аерылып торуы турында бик озак сөйләде.





***"Ашыгыз тәмле булсын!" дип кенә торалар Наилә апа белән Дания апа***

***Укучыларның татар телендә актив сөйләшә алулары максатыннан әзерләнгән сценарий. Г. Тукай әсәрләренә нигезләнеп эшләнде***

**Максат**: балаларда Габдулла Тукайның әсәрләренә, татар теленә, туган теленә, мәдәниятенә, сәнгатенә, гореф-гадәтенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Алып баручы**:Хөрмәтле балалар, олылар кыш бабайның чәчләре кар сулары булып аккан чакта, зәңгәр күк йөзендә кояш балкыган чакта, шаулап-гөрләп яз ае апрель килгәндә, безнең яраткан шагыйребез Габдулла Тукай туган.

Телсез идек-Тукай безне телле итте,
Җырсыз идек-Тукай безне җырлы итте.
*С.Кудаш.*



*Җыр "Яз җитә"*
*Җ.Фәйзи көе*
*Ф. Кәрим сүзләре.*

**Гадел:**
Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.

**Настя:**
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?-
я, әйтеп кара?

**Алеша:**
Яз килә, яз килә
Сыерчыклар килә,
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.

**Алып баручы:** Безнең татар халкы матур җырлар , шигырьләр белә. Матур итеп биюләр башкаралар. Ә хәзер безнең кызлар башкаруында чәчәкләр биюен тәгьдим итәбез.

**“Бала белән күбәләк” – җыры.**

**Элмира:**
Әйт әле, күбәләк
Сөйләшик бергәләп
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?

**Гөлкәй**:
Мин торам кырларда,
Урманда, болында.
Уйныймын,очамын
Якты көн булганда.
Шүрәле керә.

**Шүрәле**: Исәнмесез,балалар. Сез мине таныдыгызмы?

**Балалар**: Әйе,син бит Шүрәле.

**Шүрәле**: Балалар,минем уйныйсым килә,әйдәгез кети-кети уйныйбыз.

**Алып баручы:** Юк,без Шүрәле,кети-кети уенын уйнамыйбыз,әйдә “ Ачык авыз” уенын уйныйбыз.

**Уен “ Ачык авыз”.**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кулъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:
Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.
Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә кулъяулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салганны сизмәсә, аңа җаза бирелә.

**Алып баручы**:
Дуслар нишлибез,
Су анасы килә.
Су анасы керә.

**Шүрәле**: Әй син, Су анасы! Кил бирегә. Утырыйк, сөйләшик бераз.
**Су анасы**: Юк,юк. Чәчләремне тарарга,тарагымны эзлисем бар.
**Шүрәле**: Мин монда килгәндә бер тарак таптым. Синеке түгелме ул? (*күрсәтә*)
**Су анасы**: Минем тарак,минем алтын тарак. Рәхмәт, Шүрәле.
Ә мин дөрес килдемме? Тукай бәйрәменә эләктемме? Рәхәтләнеп шигырьләр тыңлар идем.
**Алып баручы**: Дөрес килдең. Безнең балалар күп шигырләр беләләр.



**Илүзә**:
Салкын кышлар үтеп
Яз килгәндә
Жылы яктан кошлар кайтканда
Туган көнең синең, бөек Тукай,
Тугры халкың итә тантана.
**раилә**:
Әле укый белмәсәк тә
“Туган телне” җырлыйбыз.
Бу Тукай абый бүләге
Иң гүзәл бер җыр дибез.
Әкиятләрен сөйләп,
Телләребез ачыла.
“Су анасы”, “Шүрәлеләр”
Безнең дуслар барсы да.
**Дима**:
И туган тел, и матур тел
Әткәм, әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.
**Рәсим**:
Туган җирем идел буе
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирем кебек назлы
Жырдай моңлы татар теле.
**Зиля**:
Татарчасы туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң – анаң, әби – бабаң,
Сине сөя торган тел.

**юля**:
Алыштырмам бу телне мин бер телгә дә,
Пычраттырмам бу телне мин бер кемгә дә.
**Су анасы**: балалар, ә сезнең арада тапкырлар бармы? Сез табышмаклар яратасызмы?
**Балалар**: әйе, яратабыз.
**Су анасы**:
Лампа түгел-яктырта
Мич түгел-җылыта. (кояш)
Сикереп тешә
Бозны тишә (тамчы)
Ишегалдында таш була
Өйгә керсә су була. (боз).
“Туган телем” җыры.
**Шүрәле**: Ә сез мәкальләр беләсезме соң?
**Алып баручы**: Әйе,беләләр.
**Витя**: Туган илем – Туган анам.
**Данил**: Туган илем – туган өем.
**Элмира**:
Иң татлы тел – туган тел
Анам сөйләп торган тел.
**Илүзә**:
Тел кешене дус итә
Бер – беренә беркетә
Яхшы беләм мин рус телен
Һәм онытмыйм үз телем.
**Ангелина**:
Татарча да яхшы бел
Русча да яхшы бел,
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.
**Гадел**:
Без татарлар, Шушы исем белә
Җирдә яшәү үзе зур бәхет.
Яшибез без бу җирдә
Бар халыклар белән берләшеп.





мин татарча сөйләшәм!

**СУ АНАСЫ уены**.
Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала “су анасы” итеп билгеләнә. Ул күзләре бәйләнгән килеш түгәрәк уртасында утыра. Уйнаучылар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр:

Су анасы, су анасы,
Су анасын күр әле.
Каршыңда кем басып тора-
Ялгышмыйча әйт әле.

Җыр ахырында балалар туктап калалар. Су анасы урыныннан тора, бармагы белән берәр уенчыга төртеп күрсәтә. әлеге бала су анасы янына килә. Су анасы, капшап карап, аның кем икәнлеген әйтергә тиеш. әгәр дөрес әйтсә шул уенчы су анасы була. Дөрес әйтмәсә, су анасы кире үз урынына утыра.
**Шүрәле**: Миңа сезнең бәйрәмегез ошады. Мин күп шигырьләр тыңладым, Туган телегезне яратасыз, Тукай абыегызны да онытмыйсыз икән.
**Су анасы**: Рәхмәт балалар. Мин үземә файдалы әйбер алдым. Җәй көнне су буена ял итәргә килегез.
**Бергә**: без сезгә күчтәнәч алып килгән идек (зур гөмбә бирәләр).
Ә хәзер сау булыгыз! (Китәләр).
“Җырлыйк әле туган телендә “ җыры.
**Алып баручы**: Шуның белән бәйрәмебез тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Бу бәйрәмне Гөльнур Айзатуллова шигырь юллары белән тәмамлыйм.

**Мин бәхетле, әгәр балаларым,**
**Сөйләсәләр ана телендә.**
**Кайгыларын, шатлыкларын бергә,**
**Бүлешсәләр татар телендә.**

мин татарча сөйләшәм!

**Г. Тукай әсәрләреннән өзекләр**

***Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр — бәхет эстәү;***
***Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак — мәгърифәт эстәү.***







***Синең кулда: теләсәң — мәгърифәтле бул, бәхетсез бул;***
***Вә яки бик бәхетле бул, ишәк***

*“Газиз телем гасыр диңгезләрен кичә-кичә килгән ерактан...”*







**Мәгълүм: дөнья көтү, заман өчен**
**файдалырак телләр бары да...**
**Тик шунсы хак: фәкать туган телдә**
**иман иңә кеше җанына!**
**(Р. Файзуллин)**





*"ТАТАР" ДИГӘН ДАНЛЫ МИЛЛӘТТӘН МИН,*
*ТУГАН ИЛЕМ, ТОРГАН ҖИРЕМ БАР!*
*БУЫННАРГА ҖИТӘР МОҢНАРЫМ БАР,*
*ГОРУРЛАНЫП ӘЙТӘМ:"МИН - ТАТАР!"*

